| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**11.10.2017 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2564** |

«Зеленодольск муниципаль районының проект офисы турында» нигезләмәне раслау хакында

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 124 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 июлендәге 203 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 231 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турында» 231 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының проект офисы турында» нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В.Кадыйровага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 11 октябрендәге 2564 номерлы карарына кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ПРОЕКТ ОФИСЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

Проект офисы-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсе системасын кертү, аңа ярдәм итү һәм үстерү өчен җавап бирә торган структур бүлекчәсе.

Проект офисы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына буйсына.

Проект офисын Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән җитәкче җитәкли.

Проект офисы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын, Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актларын кулланып эш итә.

## II. Проект офисының бурычлары һәм функцияләре

Проект офисының төп бурычлары түбәндәгеләр:

- проект эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен һәм норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру;
- Проект Комитетының утырышлар һәм карарлар проектлары өчен аналитик материаллар әзерләү, аның эшчәнлеген тәэмин итү;
- Зеленодольск муниципаль районында проект эшчәнлегенә оештыру-методик ярдәм күрсәтүне һәм идарә итүне тәэмин итү;
- Зеленодольск муниципаль районында проект эшчәнлеген оештыруга ярдәм итү;
- проект инициативаларын карау һәм проект буларак чаралар комплексын гамәлгә ашыру мөмкинлеген билгеләү;
- проектларны (проектлар портфельләрен) муниципаль реестрга кертүне тәэмин итү, паспортларны, проектларны ябу һәм кабул итү турындагы актларны (проектлар портфельләрен) раслау;
- проектларны (проектлар портфельләрен) гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;
-барлык типтагы проектлар мониторингын тәэмин итү;
- проект эшчәнлегенә идарә итү системасын үстерү буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- проект эшчәнлеге белән идарә итү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшереп тору;

- Зеленодольск муниципаль районында структур бүлекчәләрнең проект офисларын төзү турында тәкъдимнәр әзерләү;

-Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсенә укытуны координацияләү;

## III. Проект офисының хокуклары һәм вәкаләтләре

Проект офисы түбәндәгеләргә хокуклы:

-Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекчәләреннән, предприятиеләрдән һәм оешмалардан Проект офисына йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләрне һәм материалларны соратып алырга;

-билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районының планлаштырылган һәм проект эшчәнлегенә үзгәрешләр кертүне башларга;

-катнашучылар тарафыннан проектларны башкару өчен мәҗбүри булган норматив методик документларны эшләргә;

Проект офисы компетенциясендә булган мәсьәләләр карала торган киңәшмәләрдә һәм башка чараларда катнашырга;

## IV. Проект офисының составы һәм эшен оештыру

Проект офисының структурасын һәм штат санын Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы эшчәнлек шартларыннан һәм үзенчәлекләреннән чыгып раслый.

Штат расписаниесендә Проект офисы җитәкчесе позициясе структур бүлекчә җитәкчесе дәрәҗәсендә билгеләнгән. Проект офисы җитәкчесе Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына буйсына һәм Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертүне һәм идарә системасын үстерүне гамәлгә ашыра.

Проект офисының составы Проект офисы функцияләренә бәйле рәвештә формалаша һәм түбәндәге юнәлешләрне һәм рольләрне үз эченә ала:

-җитәкчелек - Проект офисы җитәкчесе һәм аның урынбасарлары;

- методологияне кертү һәм үстерү - методология буенча белгечләр (методологлар);

-эшчәнлекне планлаштыру һәм контрольдә тоту - планлаштыру (планлаштыручылар) һәм хисаплылык белгечләре;

-Проект комитеты эшен оештыру - Проект комитетының эшен оештыру белгечләре;

-проектларны гамәлгә ашыру - проектлар директорлары, проектлар җитәкчеләре, проектлар администраторлары, проектларны планлаштыру буенча белгечләр;

- мәгълүмат системасын кертү һәм үстерү - проектлар белән идарә итүнең мәгълүмат системасын кертү һәм үстерү белгечләре;

- мотивация системасын кертү һәм үстерү - мотивация системасын кертү һәм үстерү буенча белгечләр;

-укыту - укытучылар, укыту процессын оештыру белгечләре.

Проект офисы җитәкчесе:

-Проект офисының эшен оештыра һәм контрольдә тота;

-билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына Проектлы офис эшчәнлегенең ирешелгән нәтиҗәләре турында хәбәр итә;

-үз компетенциясе чикләрендә Проект офисы эшчәнлегенә кагылышлы документларны имзалый;

Проект офисының вазыйфаи затлары  Проект офисы җитәкчесе тарафыннан гамәлдәге вазыйфаи регламентлар нигезендә үзара бүленгән вазыйфаи бурычларны һәм функцияләрне башкаралар .